РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2019 елның 23 октябре

77-1 нче номерлы

Җир салымы турында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1 нче статья. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нормалары нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 нче статья. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) торак фонд һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән 0,1% (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына кагылмаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктан тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә хокуктан тыш);

2) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1% ы;

3) торак пунктлардан читтә булган җир кишәрлекләренә, категорияләренә карата кадастр бәясенең 1,5% ы: космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җир, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр, оешма һәм учреждениеләр карамагындагы сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре;

4) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составында булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләргә карата кадастр бәясеннән 0,3% ;

5) оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештәге чикләнгән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,3% ы;

6)башка җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 1,5% ы.

3 нче статья. Хисап чоры

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры булып календарь елның беренче, икенче һәм өченче кварталлары танылa дип билгеләргә.

4 нче статья. Салым ташламалары

1. Җир салымын түләүдән азат итү

1.1. Организации, учреждения в отношении земельных участков, занятых гражданскими захоронениями, за исключением случаев, предусмотренных статьей 389 Налогового кодекса Российской Федерации.

1.2. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны шәхси торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, дачалар, бакча йортлары, гаражлар һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә (өлешләргә) карата җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә. Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге территориясендә берничә җир участогы (өлеше) булган салым түләүчеләр өчен салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы (өлеш) өчен генә бирелә. Налогоплательщики - физические лица, имеющие право на налоговые льготы, установленные законодательством о налогах и сборах, представляют в налоговый орган по своему выбору заявление о предоставлении налоговой льготы, а также вправе представить документы, подтверждающие право налогоплательщика на налоговую льготу.

2. Җир салымының түбәнәйтелгән ставкасын билгеләү:

2.1. Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Буа муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, казна учреждениеләре, бюджет һәм автоном учреждениеләр җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,847% ы күләмендә;;

2.2. гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган сәнәгать җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр составындагы җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,05% ы күләмендә.

5 нче статья. Салым буенча салым һәм аванс түләү тәртибе һәм сроклары:

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче кварталлардан соң, салым чоры булган елның 1 гыйнварына җир кишәрлегенең кадастр бәясенең тиешле процент ставкасының 1/4 өлеше күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым түләү срогы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февралендә билгеләнә.

6 нчы статья. Салым түләүчеләрнең салым салу базасын киметү хокукын раслый торган документларны тапшыру тәртибе һәм сроклары

Салым базасын киметү Россия Федерациясе Салым кодексының 391 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән суммага салым түләүченең үз теләге белән салым органына тапшырыла торган салым базасын киметү хокукын раслаучы документлар нигезендә башкарыла

7 нче статья. Җир кишәрлекләренең кадастр бәясен салым түләүчеләргә җиткерү тәртибе

Җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен үткәрү нәтиҗәләре буенча, календарь елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә, агымдагы елның 1 мартыннан да соңга калмыйча салым түләүчеләр игътибарына җиткерелергә тиеш.

8 нче статья. Әлеге Законның үз көченә керүе

1. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан һәм рәсми хәбәр ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Интернет челтәрендә Буа муниципаль районының рәсми сайтында, 2019 елның салым чорында җир салымын түләүдән башлап урнаштырылган көннән үз көченә керә.

2. Әлеге карар үз көченә кергәннән соң Мөкерле авыл җирлеге Советының 2016 елның 11 октябрендәге 22-1 номерлы (тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) "Җир салымы турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Буа муниципаль районы<br>
Мөкерле авыл<br>
җирлеге башлыгы С.Н. Тюплина